**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КАДРӘК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

**№ 24** **18.09.2018 ел**

## Референдум уздыруны инициацияләү турында

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, “Җирле референдум турында” 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12 статьясы, Минзәлә муниципаль районы Уставының 12 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Кадрәк авыл җирлеге Башкарма комитеты

**КАРАР ЧЫГАРА:**

1. Җирле референдум уздыруны түбәндәге сорау буенча тәкъдим итәргә:

"Сез 2019 елда Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Кадрәк авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ яшьтән 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы, көндезге уку формасында укучы 1 төркем инвалидлардан һәм студентлардан тыш, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны юнәлтергә:

1. Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү:
   -Кадрәк авылында янгын гидранты сатып алу һәм урнаштыру
2. Ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту:
   -- Яңа Тәкермән авылында зиратны төзекләндерү, ремонтлау, Иске Мунча авылында мөселман зиратында яңа хуҗалык блогы төзү
3. Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:
   -урамнарны яктырту өчен запас җиһазлар сатып алу, агач кисү, чүплекләрне бетерү.
4. Җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне, суны чыгаруны, халыкны ягулык белән тәэмин итүне оештыру Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә:
   -сүүткәргеч трассалар, колонкалар, манаралар ремонтлау, насос сатып алу.
5. Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:
   -юлларны ремонтлау һәм тигезләү, юл кырыйларын ишелү
6. Җирлектә яшәүчеләрнең күпләп ял итүе өчен шартлар тудыру һәм халыкның күпләп ял итү урыннарын төзекләндерүне оештыру, моңа гражданнарның гомуми файдаланудагы су объектларына һәм аларның яр полосаларына ирекле керүен тәэмин итү дә керә:
   -Сабантуй үткәрү урынын төзекләндерү, бәйрәмнәр әзерләү һәм уздыру.

7. Милләтара һәм конфессияара татулыкны ныгытуга, җирлек территориясендә яшәүче Россия Федерациясе халыкларының телләрен һәм мәдәниятен саклап калуга һәм үстерүгә, мигрантларның социаль һәм мәдәни адаптациясенә, милләтара (этникара) конфликтларны профилактикалауга юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыру:
-Җәмәк авылындагы мәчетне ремонтлау.»

"ӘЙЕ " " ЮК».

2. Әлеге карар Татарстан Республикасы, Минзәлә районы, Кадрәк ав., Киров ур., 31 нче йорт, Татарстан Республикасы, Минзәлә районы, Җәмәк авылы, Ф.Галиев ур., 16А йорт адресы буенча урнаштырылган махсус мәгълүмат стендларында халыкка җиткерелергә һәм Минзәлә муниципаль районының Кадрәк авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш http://menzelinsk.tatarstan.ru

Кадрәк авыл җирлеге башлыгы Х.Х.Нәбиуллин